СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 19 » июнь 2019 ел** **№ 250**

**Арча район Советының 2016 елның 16 августындагы 70 номерлы карары белән расланган “Арча муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәне раслау турында” Арча район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (10.11.2016 №79, 05.04.2017 №119 үзгәрешләр белән)**

Арча район Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы нигезләмәнең 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Совет түбәндәге функцияләрне үти:

- федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, башка органнар һәм оешмалар эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыра;

- Арча муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыруда катнаша;

- үз компетенциясе чикләрендә коррупциячел гамәлләрне башкаруга һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү ысулларына ярдәм итә торган шартларны һәм сәбәпләрне ачыклый;

-район үсеше программалары проектларын, муниципаль хокукый актлар проектларын карый һәм җирле үзидарә органнарына тиешле тәкъдимнәр кертә;

-конференция, семинарлар, муниципаль берәмлекнең иң кискен проблемалары буенча киңәшмәләр оештыра һәм башка кызыксынган оешмалар белән берлектә үткәрә;

-кабул ителә торган карарларны нигезләү өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә оешмалардан үз компетенциясе мәсьәләләре буенча мәгълүмат соратып ала;

- җирле үзидарә органнарының халык белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

-халыкның иҗтимагый фикерен өйрәнә;

- җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары тарафыннан күрелә торган чаралар турында халыкка мәгълүмат бирә;

- район халкына үз эшчәнлеге турында хәбәр итә;

-Арча муниципаль районы халкына аларның Совет максатларына ирешүгә һәм бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән инициативаларын оештыру рәвешендә оештыруда практик ярдәм күрсәтә.

Совет, сыйфатны бәйсез бәяләүне гамәлгә ашырган очракта, үзенә йөкләнгән бурычлар чикләрендә:

- сыйфатка бәйсез бәя бирү үткәрелүче оешмаларның (учреждениеләрнең) исемлеген билгели;

- югарыда күрсәтелгән оешмалар (алга таба - оператор) тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфаты турында мәгълүматны җыюны, гомумиләштерүне һәм анализлауны гамәлгә ашыручы оешма өчен техник бирем эшләү өчен тәкъдимнәр формалаштыра, эшләр, хезмәтләр закупкалары турындагы документация проектларын, шулай ук оператор белән төзелә торган муниципаль контрактлар проектларын карауда катнаша;

- кирәк булганда, оешмалар хезмәт күрсәтүләренең сыйфатын бәяләү критерийларын билгели (федераль законнарда билгеләнгән гомуми критерийларга өстәмә рәвештә);

- иҗтимагый фикерне ачыклау, гомумиләштерү һәм анализлау, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, һөнәри берлекләр һәм башка экспертлар тарафыннан төзелгән рейтингларын төзү эшен оештыра;

- оешмаларның сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм тиешле эшчәнлеген яхшырту турындагы тәкъдимнәрне башкарма органга җибәрә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башлык урынбасары Г.Ф.Гариповага йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев